ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_29.08.2019 г._ с. Муслюмово № 464

**Мөслим муниципаль районында 2019-2020 уку елында «Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында»**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы карарын, Россия Федерациясе законнар җыентыгындагы Россия Федерациясе Оборона министры һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2010 елның 24 февралендәге 96/134 номерлы уртак боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2018 ел, 31 август, 736 нчы карарын үтәү нигезендә Мөслим муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне оештыру һәм уздыру вакытында «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законнары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1441 номерлы карары, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының № 96\134 уртак боерыгына таянып эш итәргә.

1. Кушымталарны расларга:

- 2019-2020 уку елында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планы (1 нче кушымта);
- гражданнарны хәрби хезмәткә мәҗбүри әзерләү торышын тикшереп тору, РФ Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләүне сайлап алу һәм тикшереп тору буенча Мөслим муниципаль районы комиссия составы (2 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Мөслим районы мәгариф идарәсе» МКУ, оешма, предприятие һәм учреждение җитәкчеләренә хәрби хезмәткә чакырылу яшендәге яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләүгә тулысынча җәлеп итә торган чаралар күрергә:

- белем бирү учреждениеләрен һәм оешмаларның уку пунктларын югары яки урта хәрби белеме булган запаста торучы офицерлар, шулай ук кирәкле белемнәргә ия булган һәм югары мораль-эшлекле сыйфатлары булган югары педагогик белем бирү учреждениеләренең хәрби кафедра чыгарылыш укучыларын җыеп комплектлаштырырга.
- белем бирү учреждениеләренең һәм уку пунктларының укыту-матди базасын камилләштерергә, хәрби хезмәт нигезләре буенча яшьләр белән дәресләр үткәрү өчен мәгариф учреждениеләренең спорт залларын актив кулланырга.

3. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, Башкарма комитетның яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссары, «ДОСААФ» оборона спорт - техник оешмасы, Россия Федерациясе территориясендә рөхсәт ителгән иҗтимагый һәм дини берләшмәләр белән берлектә:

- яшьләргә хәрби патриотик тәрбия бирү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне көчәйтергә, балалар һәм яшьләр өчен хәрби-патриотик берләшмәләр, клублар, секцияләр булдырырга;

- районның белем бирү учреждениеләрендә - «Аҗаган» («Зарница») патриотик уенын үткәрергә;

- төп гомуми белем, урта (тулы) гомуми белем, башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләрендә, уку пунктларында гражданнарга хәрби-патриотик тәрбия бирүне оештырырга;

- балигъ булмаган гражданнарны хәрби әзерләү максаты белән өстәмә белем бирү программалары кулланыла торган кадет класслары оештырырга, хәрби-гамәли төрләре булган спорт секцияләре, түгәрәкләр үсешенә ярдәм итәргә.

4. «Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, «Сарман Аграр көллияте» филиалы, Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариаты белән тыгыз хезмәттәшлектә:

- 2020 елның май - июнь айларында укучылар белән хәрби хезмәт нигезләре буенча җыеннар оештырырга һәм үткәрергә;

- 2020 елның августында ОБЖ (ОВС) курс укытучылары белән җыеннар оештырырга һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Х. Әхмәтов**